**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIX УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 89**

**Баек авылы** **2025 ел 17 июнь**

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Баек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының бишенче чакырылыш Баек авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Авыл утлары» («Сельские огни») газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Баек авыл җирлеге башлыгы: Фахерлегаянов М.Ф.